ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.08.2024 с.Старое Дрожжаное № 382

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 02 августындагы под-1381/24 номерлы «Мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик рекомендацияләр турында» 2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы боерыкка үзгәрешләр кертү хакында» боерыгы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 169 номерлы карары (28.08.2024 № 361 редакциядә) белән расланган Мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ составындагы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, **1 бүлекне** «1. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирә торган ведомство (тармак) бүләкләре, түбәндәге эчтәлекле **1.8-1.11 юллар** белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

| |
|---|
| «1.8. Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсендә мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. Мәгариф отличнигы |
| 1.11. Россия Федерациясенең тәрбия һәм белем бирүнең мактаулы хезмәткәре». |

2. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов